| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан**<br>**Глава Старомензелябашского**<br>**сельского поселения**<br>**Сармановского муниципального**<br>**района** | **Татарстан Республикасы**<br>**Сарман муниципаль районының**<br>**Иске Минзәләбаш авыл җирлеге**<br>**башлыгы** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел 8 ноябрь № 5

Татарстан Республикасы Сарман
муниципаль районы Иске Минзәләбаш
авыл җирлегенең Иске Минзәләбаш авылында
2023 елда үзара салым акчаларын кертү һәм
алардан файдалану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар итәм:

1.Иске Минзәләбаш авылы гражданнарның 2023 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне 2022 елның 19 ноябренә 10 сәгатькә Иске Минзәләбаш мәдәният йортында билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, I төркем инвалидлар; олы яшьтәге ялгыз гражданнар; вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар; контракт буенча хәрби хезмәт үтүче гражданнар; өлешчә мобилизаөия буенча хәрби хезмәткә чакырылганнар һәм аларның гаилә әгъзалары; чакырылганнар уку йортларының көндезге бүлекләрендә укучы студентлар; хөкем ителгәннәр; авыр тормыш хәлендә калган гаилә әгъзаларыннан (СОП, янгыннан зыян күрүчеләр) тыш, Иске Минзәләбаш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 400 сум күләмендә узара салым кертү һәм җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә тоту белән килешәсезме?:

1) Иске Минзәләбаш торак пунктының авыл эчендәге юлларны төзекләндерү (транспорт хезмәтләре, килешү буенча эшләр өчен түләү);

2) Иске Минзәләбаш торак пунктының урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам утларына хезмәт күрсәтү);

3) Иске Минзәләбаш торак пунктында халыкның күпләп ял итү мәйданы территориясен төзекләндерү ( территорияне коймаларын буяу, скамейкалар алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

4) Иске Минзәләбаш авылында массакүләм чаралар (авыл көне, Өлкәннәр көне, 9 Май, инвалидлар көне ) үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;

5) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру ( аншлаг, коймалар яңартуга буяулар алу, биек үскән агачларны кисү, килешү буенча эшләр өчен түләү);

6) Җәйге чорда Иске Минзәләбаш торак пунктында территорияне чабу (Беларусь -320.4 маркалы тракторга ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

7) Иске Минзәләбаш торак пунктында юлларны кардан чистарту (Беларусь -320.4 маркалы трактор өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

8) Иске Минзәләбаш торак пунктында чишмәләр территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу,буяу, конструкцияләрне ремонтлау, килешү буенча эшләр өчен түләү)

9) Иске Минзәләбаш авыл зиараты территориясен төзекләндерү, коймасын яңарту (төзелеш материаллары, бензопычкы алу);

10) янгынга каршы көрәш җиһазлары сатып алу

ӘЙЕ ЮК?»

3.Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә һәм Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында (http://sarmanovo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башлыгы А.Н.Габдрахманов